Республика Татарстан
**СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

РЕШЕНИЕ
22.03.2024 г.

КАРАР

№ 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Муртыш-Тамак авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 04.08.2023 N 438-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» турында, Сарман муниципаль районының «Муртыш-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Муртыш-Тамак авыл җирлеге советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Муртыш-Тамак авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 32 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Территориаль зоналар чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен кисеп үтә алмый (Россия Федерациясе Җир кодексында яисә башка федераль законда каралган очракларда чикләре территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш). Территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән файдалануның махсус шартлары булган территориаль зоналар чикләре белән кисешү рөхсәт ителә.";
2)30 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә: «- Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы территориаль планлаштыру документларындагы торак пунктлар чикләренең урнашу урыны (шул исәптән торак пунктлар) белән җир кишәрлекләре чикләре кисешкән очракта) турындагы белешмәләрнең күрсәтелгән торак пунктлар чикләренең урнашу урыны турында тасвирламасына туры килмәве, ул күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертелгәндә федераль закон нигезендә

үзгәртелде.»;

1) 2) 27 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле

2) 5.1 пункт өстәргә:

1) «5.1) әгәр мондый килештерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40_1 статьясында каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү;

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгару һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Мортыштамак авыл җирлеге
Советы рәисе И.Н.Һадиуллин